БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«____» _______ 2020 г. № _____

**«Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны штп Балтачтан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 6 сентяберендәге 294 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына үзгәреш кертү турында**

«Татарстан Республикасының район үзәкләреннән 11 километрдан ераграк урнашкан Татарстан Республикасының ерак булган һәм халык аз яши торган авыл пунктларына беренче дәрәҗәдәге кирәкле товарларны илтүгә бәйле булган кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен раслау турында» 2017 елның 20 ноябрендәге 887 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары үзгәрү сәбәпле, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. «Балтач муниципаль районы бюджетыннан беренче чиратта кирәкле товарларны штп Балтачтан 11 километрдан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы авыл пунктларына китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмаларының чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2019 елның 6 сентяберендәге 294 номерлы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- карарның исемендә һәм алга таба да текст буенча «ерак һәм аз халыклы авыл пунктлары» дигән сүзтезмәне «авыл торак пунктлары» сүзтезмәсенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район
башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф. Хәйретдинов